**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Глава**
**Балтачевского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района**

ул. Молодежная, д 1а , с. Балтачево
Азнакаевского муниципального района
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Балтач авылы жирлеге Советы башлыгы**

Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы,
Яшьлэр урамы, 1а
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октябрь 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында, Балтач авылында теркәлгән һәм А.Алиш урамы буенча 1- 25, Яшьлэр урамы 1- 70 ,Узәк урамы буенча 1- 42 ,8 Март урамы буенча 1- 37 йортлар буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының 2023 елның 20 октябрендә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Билгеләү:
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач авыл җирлегендә үзара салым кертү буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитеты.;
- гражданнар Җыенын уздыру вакыты-2024 елның 31 октябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
3.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
- 2024 елның 27 октябереннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга Балтач авылы, Молодежная урамы, 1А йорт адресы буенча бирергә.;
- Балтач торак пунктында яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия исемлекләрен төзергә;.;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Балтач торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.
4.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, гаилә әгъзасы булган гаиләләрдә көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә ризамы? мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән, бер тапкыр түләүне киметергә, аны 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләп, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тубэндэге эшлэрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү,ремонтлау ;

« РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru бүген Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) һәм Балтач авылы,Молодежная ур., 1А йорт,Центральная ур., 37 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.
6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Рәис Л.Л.Хәбипов